**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 май № 319

г. Казань

Гражданнарның аерым категорияләре өчен Татарстан Республикасының дәүләт театрларына барганда ташламалар билгеләү тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында» 2016 ел, 11 июнь, ТРЗ-43 нче Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 2 нче пункт нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнарның аерым категорияләре өчен Татарстан Республикасының дәүләт театрларына барганда ташламалар билгеләү тәртибен расларга (карарга теркәлә).
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\319.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 29 май, 319 нчы
карары белән расланды

**Гражданнарның аерым категорияләре өчен Татарстан Республикасының дәүләт театрларына барганда ташламалар билгеләү тәртибе**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гражданнарның аерым категорияләре өчен Татарстан Республикасының дәүләт театрларына барганда ташламалар билгеләү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында» 2016 ел, 11 июнь, ТРЗ-43 нче Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә эшләнде һәм гражданнарның аерым категорияләренә Татарстан Республикасының дәүләт театрларына (алга таба – театр) барганда ташламалар бирү кагыйдәләрен һәм процедурасын билгели.

1.2. Әлеге Тәртипнең максатлары булып түбәндәгеләр тора:

гражданнарның аерым категорияләренең театрларга ташлама белән бару хокукын тәэмин итү;

гражданнарның аерым категорияләренә театрларга барганда ташламалар бирү кагыйдәләрен һәм процедурасын билгеләү.

1.3. Әлеге Тәртип мәктәпкәчә яшьтәге балаларга, укучыларга, инвалидларга, инвалид балаларга, ятим балаларга, аз керемле гаиләләрдән булган балаларга, чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләргә, гражданнарның башка категорияләренә чараларга барганда театрлар тарафыннан ташламалар билгели.

II. Театрларга барганда ташламалар бирү кагыйдәләре һәм процедурасы

2.1. Әлеге Тәртип нигезендә театрлар ташламаларны бу Тәртипнең 1.3 нче пунктында күрсәтелгән гражданнарга, алар Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык) театрларга раслый торган дәүләт йөкләмәсе кысаларында үткәрелә торган театр сезонының агымдагы репертуарындагы спектакльләргә (концертларга һәм башка тамашаларга) барганда, театр җитәкчесе боерыгы нигезендә мөстәкыйль билгели.

2.2. Театр җитәкчесе боерыгында түбәндәгеләр күрсәтелгән булырга тиеш:

театрга баруга ташламалар бирелә торган гражданнар категорияләре;

театрга үзең генә һәм төркем белән баруга ташламаларның төрләре һәм күләме;

театрга баруга ташламалар бирү шартлары һәм вакыты;

аларны күрсәткәндә театрга баруга ташлама бирелә торган документлар исемлеге;

аларга барганда театрга баруга ташлама бирелә торган түләүле чаралар исемлеге.

2.3. Театрларга ташлама белән бару хокукы турында мәгълүмат театрның тамашачылар күрерлек урынында урнаштыру юлы белән театрга килүчеләр игътибарына җиткерелергә тиеш. Театрлар театрларга барганда ташламалар турындагы мәгълүматны билетлар сату урыннарында, театрларның рәсми сайтларында, массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыруны тәэмин итә.

2.4. Театрларга ташлама белән бару хокукы булган гражданнар шәхесен таныклый торган документларын һәм театрга ташлама белән бару хокукын раслый торган документларын театрлар кассаларында билет алыр алдыннан күрсәтергә тиеш.

## III. Бирелгән ташламаларны исәпкә алуны оештыру һәм аларның театрлар хисаплылыгында чагылышы

3.1. Театрларга ташлама белән бару хокукы гражданнар театрга барганда билет кенәгәсенең ертып алына торган талоны тиешенчә театрда кала һәм төгәл хисаплылык бланклары өчен билгеләнгән вакыт дәвамында саклана.

3.2. Театрлар ел саен, агымдагы календарь елының 15 гыйнварына кадәр, Министрлыкка узган ел эчендә театрларга ташлама белән бару хокукыннан файдаланган гражданнар саны турында хисап җибәрә.

3.3. Министрлык ел саен, агымдагы календарь елының 1 мартына кадәр, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына узган ел эчендә театрларга ташлама белән бару хокукыннан файдаланган гражданнар саны турында чагыштырма мәгълүмат җибәрә.

---